КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 сентябрь г.Казань № 892

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен ачыклау өчен күрсәткечләрне билгеләү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр юллары буйлап җайга салынмый торган тарифлар нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу маршрутлары буенча гомуми файдаланудагы транспортта (автобус, троллейбус, трамвай) бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (алга таба – шул ук эзлеклелектә юл йөрү билеты, балалар өчен юл йөрү билеты) белән бер тапкыр юл йөрү (транзакция) кыйммәте – 20,0 сум;

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны юллары буйлап җайга салынмый торган тарифлар нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу маршрутлары буенча автомобиль транспортында юл йөрү билеты яки балалар өчен юл йөрү билеты белән бер пассажир өчен бер километр йөрү кыйммәте – 2,4 сум.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин